КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 декабрь г.Казань № 1145

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1305 нче карары белән расланган 2023 – 2025 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1305 нче карары белән расланган 2023 – 2025 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 27 март, 364 нче; 2023 ел, 28 июнь, 764 нче; 2023 ел,

24 октябрь, 1342 нче; 2023 ел, 22 декабрь, 1669 нчы; 2024 ел, 4 май, 294 нче; 2024 ел, 18 ноябрь, 1017 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1256 нчы; 2025 ел, 11 апрель, 217 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына (алга таба – Кыска вакытлы план) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең унөченче, ундүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру 5,8 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 891 күпфатирлы йортта 205 866 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга 2026 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган 54 696,3 кв.метр гомуми мәйданлы биш күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелә.»;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Кыска вакытлы план үтәлешенең планлаштырыла торган күрсәткечләре.
2023 – 2025 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барысы | шул исәптән | | |
| | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Түбә ремонтлау, шул исәптән җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау | мең кв.метр | 919,8 | 294,1 | 317,8 | 307,9 |
| 2. | Электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | мең метр | 2 330,6 | 720,3 | 871,6 | 738,7 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | мең метр | 580,3 | 182,6 | 170,4 | 227,3 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 747,8 | 267,8 | 283,1 | 196,9 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | мең метр | 642,1 | 186,1 | 272,4 | 183,6 |
| 2.4. | су чыгару | мең метр | 339,7 | 80,5 | 142,7 | 116,5 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | мең метр | 20,7 | 3,3 | 3,0 | 14,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ бирү) өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру | данә | 78 | 23 | 26 | 29 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны көйләү узелларын урнаштыру | данә | 66 | 27 | 21 | 18 |
| 5. | Лифтларны алыштыру | данә | 1 188 | 257 | 234 | 697 |
| 6. | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау | мең кв.метр | 54,4 | 13,4 | 18,6 | 22,4 |
| 7. | Фасадны ремонтлау | мең кв.метр | 1 464,2 | 497,2 | 476,3 | 490,7 |
| 8. | Фасадны җылыту | мең кв.метр | 719,9 | 167,1 | 263,0 | 289,8 |
| 9. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | мең куб.метр | 7,1 | 0,7 | 1,6 | 4,8 |
| 10. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау | мең кв.метр | 113,2 | 25,9 | 19,9 | 67,4 |
| 11. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын ремонтлау | мең кв.метр | 80,1 | 39,7 | 30,8 | 9,6 |
| 12. | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгу юлларын ремонтлау | мең кв.метр | 8,1 | 2,2 | 2,1 | 3,8 |
| 13. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 2 364 | 726 | 747 | 891 |
| 14. | 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 720 | 720 | 0 | 0 |
| 15. | 2024 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга | данә | 747 | 4 | 743 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | | | | | |
| 16. | 2025 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 892 | 0 | 2 | 890 |
| 17. | 2026 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 5 | 0 | 0 | 5 |

Кыска вакытлы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры әлеге планның 3 нче кушымтасында китерелде.»;

V бүлектә:

икенче абзацта «25 371 659 999,75» саннарын «25 212 397 786,18» саннарына алмаштырырга;

алтынчы абзацта «15 278 609 431,28» саннарын «15 119 347 217,71» саннарына алмаштырырга;

унтугызынчы абзацта «11 266 270 913,85» саннарын «11 107 008 700,28» саннарына алмаштырырга;

егерме өченче абзацта «5 829 415 213,85» саннарын «5 670 153 000,28» саннарына алмаштырырга;

«2023 – 2025 елларда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 – 2025 елларда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Суммасы, млн.сум | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Түбә ремонтлау, шул исәптән җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау | 5 886,1 | 1 643,6 | 2 031,9 | 2 210,6 |
| 2. | Электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | 5 646,9 | 1 408,0 | 1 972,2 | 2 266,7 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | 950,8 | 255,0 | 249,6 | 446,2 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | 2 233,2 | 596,0 | 826,8 | 810,4 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | 1 144,0 | 279,8 | 452,1 | 412,1 |
| 2.4. | су чыгару | 1 273,7 | 272,8 | 439,7 | 561,2 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | 45,2 | 4,4 | 4,0 | 36,8 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) бирү өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру яки алыштыру | 28,7 | 4,1 | 5,5 | 19,1 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны көйләү узелларын урнаштыру | 71,2 | 21,6 | 25,2 | 24,4 |
| 5. | Лифтларны алыштыру | 4 311,9 | 892,9 | 865,0 | 2 554,0 |
| 6. | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау | 114,1 | 45,8 | 38,4 | 29,9 |
| 7. | Фасадны ремонтлау | 4 111,0 | 1 220,0 | 1 222,3 | 1 668,7 |
| 8. | Фасадны җылыту | 3 367,2 | 622,7 | 1 192,4 | 1 552,1 |
| 9. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | 79,7 | 16,4 | 16,9 | 46,4 |
| 10. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау | 341,4 | 66,5 | 65,2 | 209,7 |
| 11. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын ремонтлау | 69,2 | 26,7 | 26,5 | 16,0 |
| 12. | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгу юлларын ремонтлау | 52,5 | 11,0 | 23,8 | 17,7 |
| 13. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 353,1 | 85,4 | 112,2 | 155,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 14. | 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 192,6 | 192,6 | 0,0 | 0,0 |
| 15. | 2024 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 249,5 | 3,2 | 246,3 | 0,0 |
| 16. | 2025 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 328,9 | 0,0 | 1,1 | 327,8 |
| 17. | 2026 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 8,4 | 0,0 | 0,0 | 8,4 |
| 18. | Күпфатирлы йортларда 2014 елның 1 июненә кадәр урнаштырылган (алыштырылган) коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алуның күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру (алыштыру) (бары торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яки күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән) | 3,1 | 3,1 | 0,0 | 0,0 |
|  | Барлыгы* | 25 212,4 | 6 260,5 | 7 844,9 | 11 107,0»; |

Кыска вакытлы планга 1 – 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин